**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, рөхсәт ителгән ау төрләрен билгеләү турында» 2013 елның 5 апрелендәге ПУ-275 номерлы Указының 2 пунктына, «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы һәм 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2 пунктына, «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләреннән файдалану, саклау һәм урнаштыру схемасын раслау турында» 2015 елның 3 октябрендәге ПУ-968 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләреннән файдалану, саклау һәм урнаштыру схемасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: